РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«20» апреля 2021 ел г. Альметьевск № 564

Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең иң чик күләмен билгеләү турында

«Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең чик күрсәткечләрен билгеләү методикасы һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күләме нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. 2021 елга гражданнарны аз керемле дип тану турында карар кабул итү өчен, муниципаль торак фондының торак урыннарын социаль наем шартнамәләре буенча бирү нормасы буенча торак урыннар сатып алуның базар бәясенең түбәндәге чик күрсәткечләрен билгеләргә:

1.1. Гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күләме:

1.1.1. Ялгыз яшәүче граждан өчен - 1 779 327 сум;
1.1.2. Ике кешедән торган гаилә өчен – 2 264 598 руб.;
1.1.3. Өч кешедән торган гаилә өчен – 2 911 626 руб.;
1.1.4. Дүрт кешедән торган гаилә өчен – 3 882 168 руб.;
1.1.5. Биш кешедән торган гаилә өчен – 4 852 710 руб.;
1.1.6. Алты кешедән торган гаилә өчен – 5 823 252 руб.;
1.1.7. Җиде кешедән торган гаилә өчен – 6 793 794 руб.;
1.1.8. Сигез кешедән торган гаилә өчен – 7 764 336 руб.

1.2. Исәп-хисап нигезендә гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең иң чик күләмен тәшкил итә (1 нче кушымта):

1.2.1. Ялгыз яшәүче гражданга – 31 128 руб.;
1.2.2. Ике кешедән торган гаилә өчен – 19 809 руб.;
1.2.3. Өч һәм аннан да күбрәк кешедән торган гаилә өчен - 16 979 руб.

21 126

Зак. № 305-2000

2. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең иң чик күләмен билгеләү турында» 2021 елның 5 мартындагы 291 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга

3. Район Башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары А.Н. Подоваловка йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы О.Н. Шабалин

ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ

Әлмәт муниципаль районы
Башкарма комитетының
«20» апрель 2021 ел №564
карары белән расланган
1 нче кушымта

### Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең иң чик күләмен исәпләү

Граждан гаиләсенең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең иң чик күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

ПД = 0,7 х СЖ х ПС/ (1- ((1+ПС) - $^{КП}$)) / (0,3хРС), монда

ПД – гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган һәм СЖ исәп-хисап бәясе буенча торак урыны алу өчен агымдагы шартларда банкта ипотека кредиты алу өчен кирәкле уртача айлык җыелма керемнең иң чик күрсәткече;

СЖ – социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны бирү нормасы буенча торак урыны алу өчен базар хакының исәп-хисап күрсәткече, ул түбәндәге формула буенча билгеләнә:

СЖ = НП х РС х РЦ монда:

НП – гаиләнең бер әгъзасына торак урын бирү нормасы;

РС – гаилә әгъзалары саны,

РЦ – Татарстан Республикасында торак урын сатып алуга түләүсез субсидияләр исәпләү өчен тиешле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән гомуми мәйданның бер квадрат метрының уртача базар бәясеннән артмаган торак урын мәйданының бер квадрат метрының уртача исәпләнгән базар бәясе.

ПС – Бер ай эчендә кредит буенча процент ставкасы (еллык 4,25% /12 ай = 0,35%);

КП – Кредит дәвамында кредит буенча түләүләрнең гомуми саны;

РС – гаилә әгъзалары саны;

0,7 – кредит суммасының һәм фатир бәясенең нисбәте;

0,3 – кредит буенча түләүнең гаилә айлык кереме белән нисбәте.

Торак урыны мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясе Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «2021 елның I кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар хакы күрсәткечләре турында» 2020 елның 24 декабрендәге 852/пр номерлы боерыгы белән Татарстан Республикасы буенча 53 мең 919 сум күләмендә билгеләнгән.

Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең иң чик күләмен исәпләү

Табл. №1

| НП – торак урыны нормасы, (кв.м) | СЖ - торак урыны сатып алуның базар бәясе (СЖ=РСх РЦхНП), (сум) | РС – гаилә әгъзалары саны, (кеше) | РЦ - торак урынның 1 кв.м базар бәясе, (сум) | ПС - кредит буенча айлык процент ставкасы, % | КП - кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (ай) | Кредит суммасы һәм фатир бәясенең нисбәте | Кредит буенча түләүнең җыелма айлык кереме белән нисбәте | ПД-керемнең иң чик кыйммәте (сум) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| | | | 53 919 | 4,25/12 /100= 0,0035 | 180 | 0,7 | 0,3 | |
| 33 | 1 779 327 | 1 | 53 919 | 0,0035 | 180 | 0,7 | 0,3 | 31128 |
| 42 | 2 264 598 | 2 | 53 919 | 0,0035 | 180 | 0,7 | 0,6 | 19809 |
| 54 | 2 911 626 | 3 | 53 919 | 0,0035 | 180 | 0,7 | 0,9 | 16979 |
| 72 | 3 882 168 | 4 | 53 919 | 0,0035 | 180 | 0,7 | 1,2 | 16979 |
| 90 | 4 852 710 | 5 | 53 919 | 0,0035 | 180 | 0,7 | 1,5 | 16979 |
| 108 | 5 823 252 | 6 | 53 919 | 0,0035 | 180 | 0,7 | 1,8 | 16979 |
| 126 | 6 793 794 | 7 | 53 919 | 0,0035 | 180 | 0,7 | 2,1 | 16979 |
| 144 | 7 764 336 | 8 | 53 919 | 0,0035 | 180 | 0,7 | 2,4 | 16979 |

Район
Башкарма комитеты җитәкчесенең
икътисад буенча урынбасары
вазифаларын башкаручы Р.Ф. Камалов